ГОСУДАРСТВЕННАЯ ИНСПЕКЦИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ОБЕСПЕЧЕНИЮ
ГОСУДАРСТВЕННОГО КОНТРОЛЯ
ЗА ПРОИЗВОДСТВОМ, ОБОРОТОМ И
КАЧЕСТВОМ ЭТИЛОВОГО СПИРТА,
АЛКОГОЛЬНОЙ ПРОДУКЦИИ
И ЗАЩИТЕ ПРАВ ПОТРЕБИТЕЛЕЙ
(Госалкогольинспекция Республики Татарстан)

Х. Такташа ул., 94, а/я 44, Казань, 420107

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ЭТИЛ СПИРТЫ ҺӘМ АЛКОГОЛЬЛЕ
ПРОДУКЦИЯ ЖИТЕШТЕРҮНЕ,
ӘЙЛӘНЕШТӘ ЙӨРТҮНЕ,
СЫЙФАТЫН ДӘҮЛӘТ ТИКШЕРҮЕН
ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ КУЛЛАНУЧЫЛАР
ХОКУКЛАРЫН ЯКЛАУ БУЕНЧА
ДӘҮЛӘТ ИНСПЕКЦИЯСЕ
(Татарстан Республикасы дәүләт алкоголь
инспекциясе)

h Такташ урамы, 94 нче йорт, Казан шәһәре, 420107

тел. (843) 278-92-00, факс (843) 278-91-92, e-mail: cla@tatalc.ru, http://www.tatalc.ru,
ОКПО 42151664, ОГРН 1021602865239, ИНН/КПП 1654025044/165901001

**БОЕРЫК**

26.08.2016 №12-07/74

Вазыйфалар исемлеген
раслау турында

“Россия Федерациясендә дәүләти гражданлык хезмәте турында” 27 июль, 2004 ел, №79-ФЗ Федераль законны, “Коррупциягә каршы көрәш турында” 25 декабрь, 2008 ел, № 273-ФЗ Федераль законны, “Коррупциягә каршы көрәш турында” Федераль законның кайбер нигезләмәләрен тормышка ашыру чаралары турында” 30 сентябрь, 2010 ел, № УП-636 Татарстан Республикасы Президенты Указын, “Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан үзенең керемнәре, милке һәм мөлкәт характерындагы бурычлары, шулай ук үзенең хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, милке һәм мөлкәт характерындагы бурычлары турында мәгълүматлар тапшыруны таләп иткән Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында” 30 декабрь, 2009 ел, № УП-701 Татарстан Республикасы Президенты Указын, “Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан үзенең керемнәре, милке һәм мөлкәт характерындагы бурычлары, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан үзенең керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәт характерындагы

бурычлары турында мәгълүматлар тапшыру хакында” 30 декабрь, 2009 ел № УП-702 Татарстан Республикасы Президенты Указын үтәү йөзеннән һәм Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең 26.08.2016 ел, №12-07/73 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасының Этил спирты һәм алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне, сыйфатын дәүләт тикшерүен тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясенең (алга таба - Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе) штат расписаниесен гамәлгә кертүгә бәйле рәвештә, “Татарстан Республикасының Этил спирты һәм алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне, сыйфатын дәүләт тикшерүен тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе мәсьәләләре” 05.08.2005 ел, №391 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү турында” 26.08.2016 ел, №593 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә коррупция куркынычы белән бәйле булган вазыйфаларны биләүче Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан үзенең керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәт характерындагы бурычлары, шулай ук үзенең хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары милке һәм мөлкәт характерындагы бурычлары турында мәгълүматлар тапшыруны таләп иткән Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфалары исемлеген (алга таба – Вазыйфалар исемлеге) (кушымта итеп бирелә) расларга.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе аппаратының кадрлар сәясәте һәм коррупциягә каршы көрәш бүлегенә бу боерыкны дәүләти гражданлык хезмәткәрләре игътибарына җиткерергә, шулай ук Вазыйфалар исемлегенә кертелгән, вазыйфалар биләүче дәүләти гражданлык хезмәткәрләренә “Коррупциягә каршы көрәш турында” 25 декабрь, 2008 ел, № 273-ФЗ Федераль законның 12 статьясында күздә тотылган чикләүләрне, бурычларны һәм җаваплылыкны аңлатырга.

3. Административ һәм суд практикасы бүлегенә (Эйдинов Б.Г.) бу

боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәвенә алуны хәл итәргә.

4. “Вазыйфалар исемлеген раслау турында” 24 сентябрь, 2010 ел, № 176 Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе боерыгын үз көчен югалткан дип танырга.

5. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Җитәкче** **И.А.Марченко**